**СОВЕТ УРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**423706,Республика Татарстан, Мензелинский район, д. Урусово, ул. Дружбы, 42**

**423706, Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Урыс авылы, Дружбы урамы,42**

ОКПО 4308290 телефон: (85555)2-79-86 ОГРН 1021605552880 E-mailUrus.Mnz@tatar.ru ИНН/КПП 1628002805/162801001

# КАРАР

**26 ноябрь, 2019 ел.** **№ 1**

## Җир салымы турында

Россия Федерациясе Салым Кодексының 31 бүлеге, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләнергә тиеш җир салымын билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

**2.** Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

- карьерлар эшкәртелеше өчен (гомуми таралган файдалы казылмаларны чыгару) җирле үзидарә органы билгеләгән һәм файдалана торган җир кишәрлекләренә карата - 0,03%;

- 1-3 категориядәге гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары төзелешенә һәм эксплуатацияләүгә бирелгән җир кишәрлекләренә карата - 0,05% ;

- кунакханәләр урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 0,1%;

- күпкатлы торак төзелеше, шәхси торак төзелеше йортларын урнаштыру өчен билгеләнгән, **эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган** җир кишәрлекләренә карата, шул исәптән, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 0,15%”.

- бакчачылык һәм яшелчәчелек өчен билгеләнгән, **эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган** җир кишәрлекләренә карата, шулай ук дача, бакчачылык һәм яшелчәчелек берләшмәләре составында булган җир кишәрлекләренә карата - 0,3%;”

**- торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата - 0,3%** (торак фондына карамаган объектка һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына туры килгән) яисә (эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлегенә хокукта өлештән тыш);

**- авыл хуҗалыгы билгеләнешенә кертелгән яисә авыл хуҗалыгы файдалануы зонасы составындагы һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җир кишәрлекләренә карата - 0,3%.**

**- саклануны, иминлекне һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән, Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата – 0,3%;**

- мәгариф, фән, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэминат, физик культура һәм спорт, сәнгать, дини объектларның, стационар һәм палатка туристик-сәламәтләндерү һәм спорт лагерьлары административ һәм офис биналарын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 0,4%;

- сәнәгать, коммуналь хуҗалык, матди-техник, азык-төлек белән тәэмин итү, сату һәм әзерләү җитештерү һәм административ биналар, корылмаларны урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 1,0%;

- сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 1,2%;

- авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланылмый торган авыл хуҗалыгы файдалануындагы җир кишәрлекләренә карата - 1,5%;

- гараж һәм автомобиль кую урыннарын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата - 1,5%;

- башка җир кишәрлекләренә карата - 1,5%.

**3**. Түбәндәге категориягә керүче салым түләүчеләрне җир салымын түләүдән азат итәргә:

1) гражданнарны җирләү урыннары, парклар, скверлар, бульварлар, яр буйлары, чишмәләр, суүтем башнялары, скважиналар, һәйкәлләр, **пляжлар** биләгән җир кишәрлекләренә карата оешмалар, учреждениеләрне.

2) 90 яшькә җиткән һәм аннан өлкән яшьтәге гражданнарны;

3) Бөек Ватан сугышында катнашкан инвалидларны һәм ветераннарны; 4) Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә бирелгән җирләр буенча күпбалалы гаиләләрне.

4. Календарь ел салым чоры дип таныла. Календарь елның беренче кварталын, икенче кварталын һәм өченче кварталын салым түләүче оешмалар өчен отчет чоры дип танылуын билгеләргә.

**5.** Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү тәмамланган отчет кварталыннан соң килүче икенче айның 5 нче числосыннан соңармыйча, беренче, икенче, өченче квартал тәмамлангач, җир кишәрлегенә кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасының ¼ күләмендә аванс түләүләр аша гамәлгә ашырыла.

Салым чоры нәтиҗәләре буенча түләнергә тиешле салым суммасы тәмамланган салым чорыннан соң килүче елның 5 февраленнән соңармыйча түләнә.

6. “Җир салымы турында” 2018 елның 16.11. 1 номерлы Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Карарын көчен югалткан дип танырга.

7. Гамәлдәге Карар 2020 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

8. Гамәлдәге Карар рәсми төстә басылырга тиеш.

9. Гамәлдәге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз карамагыма алам.

Урыс авыл җирлеге Башлыгы,
Минзәлә муниципаль районының
Урыс авыл җирлеге Советы рәисе Ф.М. Маулин